| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ТАТАРСКО-КАНДЫЗСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАТАР КАНДЫЗЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 января 2016 ел. Татар Кандыз авылы № 23

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы Татар Кандызы
авыл җирлеге территориясендә
гражданнарның үзара салымын кертү
мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Татар Кандызы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге Советының 2014 елның 26 февралендәге 72 номерлы «Татар Кандызы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын арттыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге Советы Татар Кандызы авыл җирлеге Советы
Карар Итэ:
1.2016 елның 13 мартына Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2.Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«2016 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәм җирле әһәмияткә ия

булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Татар Кандызы авылында капиталь ремонт-93400 сум;

ЮК ЭЙЕ

3.Әлеге карар Татар Кандызы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Татар Кандызы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Татар Кандызы авылы, Совет урамы, 166 йорт;

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татар Кандызы авыл җирлеге башлыгы М. Ш. Насыйбуллин